РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

*Решение* *Карар*

2019 елның 27 декабре Чистай шәһәре № 51/2

«Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында»гы 2015 елның 27 февралендәге 43/4 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 27.02.2015 № 43/4 карары белән расланган Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында Положениегә (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2015 елның 11 мартындагы 43/4 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 38/3 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 пунктның 1.1 пунктчасында «орган булып тора» сүзләреннән соң «җирле үзидарә» сүзләрен өстәргә;

1.1. 3 пунктта:
1.2.1. 3.1.12 пунктчасында «гамәлгә ашыра» сүзеннән соң «муниципаль» сүзен өстәргә;
1.2.2. 3.1.27.2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;
1.2.3. түбәндәге эчтәлекле 3.1.27.3 пунктча өстәргә:
«3.1.27.3. бюджет вәкаләтләрен үтәү сыйфатын мониторинглауны үз эченә алган финанс менеджменты сыйфаты мониторингы үткәрә, шулай ук җирле бюджет акчаларының баш администраторларына карата билгеләнгән тәртиптә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру активлар белән идарә итү сыйфаты үткәрә;»;

1.2. 5 пунктның 5.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.1. Палатаны Палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче һәм аның эшен оештыручы җитәкче җитәкли. Палата җитәкчесе Чистай муниципаль районы Советы вазыйфасына

Чистай муниципаль районы башлыгы тәкъдиме белән билгеләнә. Палата җитәкчесе җирле үзидарә органының вазыйфаи заты булып тора.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының 1.2.2. һәм 1.2.3 пунктчалары 2020 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2015 елның 27 февралендәге 43/4 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмәгә әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнага йөкләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А.Иванов